ПРОЕКТ

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Пычак авыл җирлеге Советы

# КАРАР

Пычак авыл җирлеге Советының 2007 елның 28 сентәберендәге 26 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлегендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

23 сентябрь 2021 № 16

Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлегендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Пычак авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Пычак авыл җирлеге Советының 2007 елның 28 сентәберендәге 26 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлегендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

а) 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү турындагы карар Пычак авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Гражданнардан сораштыруны билгеләү турындагы карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыру уздыру датасы һәм сроклары;

2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формулировкалау;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең формасы;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.

б) 19 статьяның 1 пунктында «яисә муниципаль берәмлек халкы» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Пычак җирлек башлыгы Г.Ш.Нафиков